| Республика Татарстан<br>Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районынын Иске Имэн авыл жирлеге |
|---|---|
| **КАРАР**<br>**13.08.2025 ел** | **КАРАР**<br>**№ 12** |

Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 5 апрелендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең "Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 5 апрелендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Карарның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Кулланучыларга терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында мәгълүмат бирү әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Ә.Исламова